**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

№ 47-Р 2019 елның 29 июленнән

# РЕШЕНИЕ

# КАРАР

**Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Хәерби авыл җирлегендә
җирдән файдалану һәм
төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында**

Муниципаль берәмлекләр территорияләренең тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау, Муниципаль берәмлекләр территорияләрен планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының иң нәтиҗәле төрләрен сайлап алу мөмкинлеген бирү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30, 33, 30 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә, халык тыңлауларын үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып,Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен расларга.

2. «Кама ягы» газетасында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча әлеге карарны бастырырга (халыкка җиткерергә): http://pravo.tatarstan.ru һәм Лаеш муниципаль районы сайтында Интернет-телекоммуникация челтәре веб-адресы буенча урнаштырырга: http://laishevo. tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Лаеш муниципаль районы Советының җирдән файдалану, төзелеш, төзекләндерү һәм экологик куркынычсызлык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе М. П. Афанасьев**